**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 № 962

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 525 номерлы карары белән расланган «Рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау хакында»рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 525 номерлы карары белән расланган «Рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау хакында»рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5.1нче пунктта:

а) 1нче пунтчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны теркәү вакытын бозу;";

б) 3нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны гамәлгә ашыру яисә гамәлләрне башкару таләп итү;";

в) 5нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;";

г) түбәндәге эчтәлекле 8, 9, 10 пунктчалар өстәргә:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;";

10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда дөрес булмавы һәм (яки) булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш;";

2) 5.7нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль

норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма формада һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 5.8, 5.9 пунктлар өстәргә:

“5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарылырга тиешле алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

4) 5.8нче пунктны 5.10нчы дип санарга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы иципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы М.Х. Хәбибуллова